# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Биләр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Биләр авыл торак пунктында
2023 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2022 елның 14 октябреннән** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Биләр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Биләр авыл торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елда Алексеевск муниципаль районының «Биләр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Биләр авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Садовая урамы, Ленин урамы, Бутлеров урамы, җирлек эчендәге юлларны төзү (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эш хакын килешү буенча түләү)
- җәйге чорда грейдерлау һәм территорияне чабу (
ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- кышкы чорда җирлек эчендәге юлларны чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- тракторны карап тоту (запас частьләр сатып алу, ЯММ, хезмәткә түләү);
- күмү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү (авария хәлендәге агачларын кисү һәм җыештыру, килешү буенча түләү);
- урам утларын карап тоту (лампаларны ремонтлау, сатып алу);
- сууткәргечне карап тоту, су башнясын күчерү.
- зур күләмле чүпләрне җыю,чыгару (айга бер тапкыр ) .

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Биләр авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Биләр авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Биләр авыл җирлеге башлыгы Хәбибуллин Г.Г.
бибуллин

СОВЕТ БИЛЯРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ